Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кичү авыл Советы

КАРАРЫ

26 сентябрь 2023 ел № 74

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кичү авыл Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында» 2022 елның 20 январендагы 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 6 февралендәге 12-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 6 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

Кичү авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кичү авыл Советы депутаты статусы турында нигезләмә хакында» 2022 елның 20 январендагы 29 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кичү авыл Советының 2022 елның 13 июлендәге 41 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга кушымтада:

а) «Депутат тикшерүе» 10.3 статьясын төшереп калдырырга;

б) 14 статьяны түбәндәге эчтәлекле 1.1. өлеше белән тулыландырырга:

«1.1. Җирлек Советының барлык утырышларында алты ай рәттән җитди сәбәпләрсез депутат булмаган очракта җирлек Советы депутаты вәкаләтләре җирлек Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

в) 14 статьяның 2 өлешендәге икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

г) 17 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктының «а» пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга.;

д) 17 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктының «б» пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп

калдырырга, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга;

е) 17.1 статьясының 1 өлешендәге 1 пунктын «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

ж) 17.1 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «яисә дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү» сүзләрен «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган белешмәләр бирү яисә белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү» сүзләренә алмаштырырга;

з) 17.1 статьясының 2 өлешен «Федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

2. Әлеге карарны Кичү авылы, Үзәк урам, 50 нче йорт; Нагорное авылы, Үзәк урам, 17 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә .

Кичү авыл җирлеге башлыгы Г.П.Туманова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КИЧУЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»
КИЧУЙСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ